Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

2018 елның 20 сентябре № 17

## Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы “Җирле референдум турында” законының 12, 17 статьялары, Татар Тау Иле авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татар Тау Иле авыл җирлеге Советы белән берлектә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итәргә: “2019 елда яшәү урыны Татар Тау Иле авыл җирлеге чикләрендә урнашкан, 18 яшькә җиткән һәр Россия Федерациясе гражданыннан 500 сум үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны киләсе эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме:

- Татар Тау Иле һәм рус Тау Иле авылларында зиратларны койма белән әйләндереп алу;
- Татар Тау Иле авылында спорт мәйданчыгын төзекләндерү.

Аерым мәсьәләләр буенча акча экономияләнгән очракта, Татар Тау Иле авыл җирлеге башкарма комитетына референдум тарафыннан билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә,

ӘЙЕ ЮК”.

2. Әлеге карарны Татар Тау Иле авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Татар Тау Иле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Г.Н. Шаров

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ТАТАРСКО-ХОДЯШЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ ТАТАРСКО-ХОДЯШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000948